ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.03.2022 ел Баулы шәһәре №46

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 8 маендагы 102 номерлы карары белән расланган “2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү” муниципаль программасына (2020 елның 17 июлендәге 142 номерлы, 2021 елның 19 февралендәге16 номерлы, 2021 елның 23 декабрендәге 233 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2023 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары нигезендә, физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, Баулы муниципаль районы территориясендә физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 8 маендагы 102 номерлы карары белән расланган “2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү” муниципаль программасына (2020 елның 17 июлендәге 142 номерлы, 2021 елның 19 февралендәге16 номерлы, 2021 елның 23 декабрендәге 233 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп

финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләме | Программаны финанслауның гомуми күләме 2020-2024 елларда 318 905,53 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2020 ел - 61 897,70 мең сум;<br>2021 ел - 76 361,92 мең сум;<br>2022 ел - 60 454,71 мең сум;<br>2023 ел - 60 095,60 мең сум;<br>2024 ел - 60 095,60 мең сум.<br>Искәрмә:<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Баулы муниципаль районы бюджеты проектын тиешле елга һәм план чорына формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. Республика, җирле бюджетлар акчалары ел саен төзелгән шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк". |

III «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне җайга салу» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Программаны финанслауның гомуми күләме 2020-2024 елларда 318 905,53 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:
2020 ел - 61 897,70 мең сум;
2021 ел - 76 361,92 мең сум;
2022 ел - 60 454,71 мең сум;
2023 ел - 60 095,60 мең сум;
2024 ел - 60 095,60 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Баулы муниципаль районы бюджеты проектын тиешле елга һәм план чорына формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. Республика, җирле бюджетлар акчалары ел саен төзелгән шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк".

VI «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына чаралар исемлеге» бүлегендә:

III бүлек. «2020-2024 елларга спорт резервын әзерләү буенча югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү» ярдәмче программасы чаралары исемлеген яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Ел саен Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасында чираттагы финанс елына Баулы муниципаль районы бюджетын формалаштырганда әлеге карарның

1 пункты нигезендә Программа чараларын тормышка ашыру өчен акча бүлергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 14 мартындагы
46 номерлы карары белән
расланган

«VI. 2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү " муниципаль программасы чаралары исемлеге

III. "2020-2024 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү" ярдәмче программасы чаралары исемлеге

| № п/п | Чара атамасы | Җаваплы башкаручылар | Башкару срогы | Финанслау чыганагы, күләме | Шул исәптән, еллар буенча (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1. | Спорт мәктәпләрен махсус җиһазлар, спорт инвентарьлары һәм экипировка белән тәэмин итү | “1 нче спорт мәктәбе” МБУ “2 нче спорт мәктәбе” МАУ “3 нче комплексלы спорт мәктәбе” МАУ | 2020-2024 еллар | республика бюджеты | 335,40 | 372,55 | 366,41 | - | - |
| 2. | Хоккей буенча Татарстан Республикасы һәм Россия беренчелегендә (А төркеме) катнашу | “3 нче комплекслы спорт мәктәбе” МАУ | 2020-2024 еллар | республика бюджеты | 272,40 | 327,90 | 234,3 | - | - |
| 3. | Баулы муниципаль районы территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-савыктыру һәм | “1 нче спорт мәктәбе” МБУ каршындагы модульле чаңгы базасы | 2020-2024 еллар | республика бюджеты | 697,79 | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тәэмин итү | | | | | | | | |
| 4. | Югары клалификацияле спортчылар әзерләгән спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче тренерларны, шулай ук ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен спортчыларны, спортчы – инструкторларны бүләкләү | “1 нче спорт мәктәбе” МБУ<br><br>“2 нче спорт мәктәбе” МАУ | 2021-2024 еллар | республика бюджеты | - | 143,94 | 300,0 | - | - |
| 5. | Физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль биремне үтәү максатларында спорт объектларының террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга | “1 нче спорт мәктәбе” МБУ<br>“3 нче комплекслы спорт мәктәбе” МАУ | 2021-2024 еллар | республика бюджеты | - | 495,5 | - | - | - |
| БАРЛЫГЫ: | | | | | 1305,59 | 1339,89 | 900,71 | - | - » |